ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.10.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№2457**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2004 елның 30 декабрендәге «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 214-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 16.10.2019 ел, №2181, 20.03.2020 ел, №574, 14.12.2020 ел, №2436, 10.09.2021 №2208 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1 Административ регламентның 1.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Өлешле төзү турындагы законнарда билгеләнгән неустойканы (штраф, пеня), башка финанс санкцияләрне,шулай ук , өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкның башка чараларын куллану үзенчәлекләрен билгеләү турында, һәм күпфатирлы йортларның һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең проблемалы объектларын реестрга кертү үзенчәлекләре турында һәм төзүче тарафыннан 6 айдан артык күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзеп бетерү (төзү) вакыты һәм (яки) өлешле төзелеш объектын өлешле төзүдә катнашуның теркәлгән килешүе буенча өлешле төзүдә катнашучыга тапшыру бурычлары бозылган күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез мөлкәт объектларын төзүче тарафыннан реестрга кертү үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 02 апрелендәге 423 номерлы карары белән;

«2020 елда дәүләт контролен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

1.2 Административ регламентка 5 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Төзүче тарафыннан төзүчегә туры килүе турында бәяләмә бирү һәм проект декларациясе бирү өчен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьяның 1.1 һәм 2 өлешләрендә 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү турында документлар исемлеге».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http: zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев